Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 5**

Олы Солтан авылы 2026 елның 14 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 маендагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга акчалата бүләкләүләрне, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездәге муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә алыштырып торучы затларның, социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы түләү системасы үзгәрү сәбәпле, в «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 ел, №182, "Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 29.12.2005 ел, № 666, "Татарстан Республикасы дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 10.07.2006 ел, № 353, 2025 елның 25 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының, аудиторларының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» үзгәрешләр кертү

хакында»гы 994номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карар**лары**ы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Олы Солтан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 маендагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга акчалата бүләкләүләрне, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” 7 номерлы карарына (29.09.2020 елгы №2; 14.10.2024 елгы №12, 04.02.2025 елгы № 2 редакцияләрендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме һәм шартлары» диелгән 1 нче кушымтада авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләме 23201 сум дип билгеләргә;

1.2) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Солтан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре» диелгән 2 нче кушымтаның 2 пунктында «15 389,0» санын «16 928,0» санына алмаштырырга;

1.3) "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгәннәре өчен бүләкләр түләү күләме һәм тәртибе" 5 нче кушымтасының 2 нче пункты түбәндәге эчтәлектәге 3 нче абзац белән тулыландырылсын:

"Премия Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең спартакиадасы кысаларында спорт төрләре буенча ярышларда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җыелма командасы составында катнашкан муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бирелә"

2. Әлеге карар үзенең гамәле белән 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. дип билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р. Шәрәфеев урамы, 12 нче йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Б.М.Зәйнуллин

СОВЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000725 ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ